Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча**
**төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә**
**дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**ГЕОГРАФИЯ буенча**
2016 елда төп дәүләт имтиханы (ТДИ) үткәрү өчен
контроль үлчәү материаллары (КҮМ)
**үзенчәлекләре (спецификация)**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде

# ГЕОГРАФИЯ
# буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль үлчәү материаллары үзенчәлекләре

**1. ТДИ өчен КҮМның билгеләнеше** – IX чыгарылыш сыйныф укучыларының география буенча гомумбелем бирү программасын үзләштерү дәрәҗәсен дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү аша бәяләү. Имтихан нәтиҗәләре укучыларны урта мәктәпнең профильле сыйныфларына кабул иткәндә файдаланылырга мөмкин.

ТДИ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә үткәрелә.

**2. КҮМ эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты базасында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2004 елның 5 мартындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми мәгариф дәүләт стандартлары федераль компонентын раслау турында» 1089 номерлы боерыгы) нигезендә билгеләнде.

**3. КҮМ эчтәлеген сайлауга, структурасын эшләүгә карашлар**

2016 нчы елгы ТДИ өчен имтихан эшендә тикшерелергә тиешле эчтәлекне сайлау, төп белем бирү программалары эчтәлегенең мәҗбүри минимумы һәм чыгарылыш сыйныф укучысының география буенча төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты Федераль компонентына туры китереп башкарылырга тиеш.

2016 нчы ел КҮМның һәр вариантына төп мәктәп өчен география курсының барлык төп бүлекләренең эчтәлеген тикшерүгә биремнәр һәм чыгарылыш сыйныф укучысының әзерлек дәрәҗәсенә төп таләпләрне үтәү кертелгән.

**4. ТДИ эше моделенең БДИ КҮМы белән бәйләнеше**

ТДИ КҮМның күпчелек өлеше БДИ эшләрендә кулланыла торган биремнәр белән бер төрле. БДИнан аермалы буларак, ТДИ өчен КҮМнарда игътибар күбрәк укучыларның географик белем һәм осталыкларын гамәли кулланылышка юнәлдерелгән таләпләрне үтәүгә юнәлтелә.

Шулай ук ТДИ өчен төрле чыганаклардан географик мәгълүматларны (атлас карталары, статистик материаллар, диаграммалар, массакүләм мәгълүмат чараларыннан текстлар) эзләп табу һәм анализлау осталыгы формалашканлыкны тикшерү планлаштырыла.

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

**5. КҮМның төзелеше һәм эчтәлеге характеристикасы**

Имтихан эше 30 биремнән тора. Биремнәр укучыларның географик грамоталылыгының нигезен тәшкил итә торган белемнәрен, шулай ук мәктәп курсының төп бүлекләрендә чагылыш тапкан белем һәм осталыкларны контекстта куллана алуларын тикшерәләр.

Эш кыска җавап язуны таләп иткән 27 биремнән тора, шулардан 17 биремгә җавап бер цифр рәвешендә языла, 3 биремнең җавабы сүз яки сүзтезмә рәвешендә языла, 7 биремгә сан яки цифрлар эзлеклелеге рәвешендәге җаваплар бирелә, 3се – куелган сорауга тулы һәм нигезле җавап бирүне сорый торган бирем.

**6. КҮМ биремнәрен эчтәлекләре, тикшерелә торган осталыклары һәм эшчәнлек ысуллары буенча**

Биремнәрне төп мәктәптә география курсының аерым бүлекләренең эчтәлеген белү дәрәҗәсен тикшерүгә юнәлдерелгән биремнәргә таркату 1 таблицада бирелгән.

| География буенча төп гомуми белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы бүлеге | Биремнәр саны[1] | Максималь беренчел балл | Барлык эш өчен куелган 32 баллга тигез булган максималь беренчел баллдан әлеге бүлекнең биремнәре өчен максималь беренчел баллның процент |
|---|---|---|---|
| 1. Географик мәгълүматның чыганаклары | 6 | 6 | 19 |
| 2. Җир табигате һәм Кеше | 7 | 8 | 25 |
| 3. Материклар, океаннар, халыклар һәм илләр | 2 | 2 | 6 |
| 4. Табигатьтән файдалану һәм геоэкология | 2 | 2 | 6 |
| 5. Россия географиясе | 13 | 14 | 44 |
| Барысы | 30 | 32 | 100 |

Имтихан эше биремнәренең осталык төрләре һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүленешләре 2 таблицада бирелгән.

[1] Күрсәтелгән бүлекләр буенча имтихан вариантларында биремнәр саны төрлечә булырга мөмкин (кара: Кушымта)

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

*Таблица 2. Имтихан эше биремнәренең осталык төрләре*
*һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүленеше*

| Төп осталыклар һәм эшчәнлек ысуллары | Биремнәр саны | Беренчел максималь балл | Барлык эш өчен куела торган, 32 баллга тигез булган беренчел максималь баллдан уку эшчәнлегенең әлеге төр биреме өчен максималь беренчел балл проценты |
|---|---|---|---|
| 1.«Белергә/аңларга» таләбе | 13 | 13 | 40,6 |
| 2. «Эшли алу» таләбе | 14 | 15 | 46,9 |
| 3. «Алган белемнәрне һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта» куллану» таләбе | 3 | 4 | 12,5 |
| Барысы | 30 | 32 | 100 |

**7. КҮМ биремнәрен катлаулылык дәрәҗәләре буенча бүлү**

Эштә база дәрәҗәсендәге, катлаулы һәм югары катлаулылыктагы биремнәр файдаланыла. База дәрәҗәсендәге биремнәрне башкаруның планлаштырылган процентлары 60-90; катлаулыларының 40-60; югары катлаулылыктагыларын 40 процентган ким булырга тиеш түгел. КҮМ биремнәренең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше 3 таблицада күрсәтелгән.

*Таблица 3. Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәләре буенча бүленеше*

| Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәләре | Биремнәр саны | Максималь беренчел балл | Барлык эш өчен куела торган 32 баллга тигез булган максималь беренчел баллдан әлеге дәрәҗәдәге катлаулылыктагы бирем өчен максималь беренчел балл проценты |
|---|---|---|---|
| Нигез | 17 | 17 | 53,1 |
| Катлаулы | 10 | 11 | 34,4 |
| Югары катлаулылыктагы | 3 | 4 | 12,5 |
| Барысы | 30 | 32 | 100 |

## 8. География буенча ТДИ дәвамлылыгы

Имтихан эшен башкару өчен 120 мин. вакыт бирелә.

**9. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Укучыларга линейкалар, программалаштырылмаган калькуляторлар һәм VII, VIII, IX сыйныфлар өчен (теләсә кайсы нәшриятта басылган) географик атласлардан файдаланырга мөмкин

**10. Аерым биремнәрнең үтәлешен һәм тулаем имтихан эшен бәяләү системасы**

Кыска җавап таләп итә торган биремнәр җаваплар эталоны белән чагыштыру юлы аша тикшереләләр. Киңәйтелгән җавап таләп ителә торган биремнәрне экспертлар махсус эшләнелгән критерийлар исемлеге нигезендә тикшерәләр.

Биремнең үтәлеше аның тибына, катлаулылыгына бәйле рәвештә төрле баллар белән бәяләнә. Кыска җавап таләп итә торган һәм дөрес башкарылган һәр биремгә 1 балл куела. Киңәйтелгән җавап таләп итә торган (15, 20) биремнәрне башкаруга, җавапларның тулылыгына һәм дөреслегенә бәйле рәвештә 0 дән алып 2 баллга кадәр, 23 нче биремне эшләгән өчен 1 балл куела. Барлык имтихан эшен башкару өчен максималь беренчел балл– 32 балл.

Төп гомуми белем мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

15, 20 нче биремнәрне үтәгән өчен куелган баллар арасындагы аерма 2 балл булса, өченче эксперт, бары тик шундый зур аерма китереп чыгарган биремне генә тикшерә.

**11. 2016 елгы КҮМ да 2015 ел белән чагыштырганда күзәтелгән үзгәрешләр**

КҮМның структурасында һәм эчтәлегендә үзгәрешләр күзәтелми.

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте

*Кушымта*

## IX сыйныфны тәмамлаучыларга ГЕОГРАФИЯ буенча ТДИ өчен КҮМ вариантының гомумиләштерелгән планы

| № п/п | Эшчәнлекнең контрольгә алынган төрләре | Контрольгә алынган эшчәнлек төренең коды | Эчтәлекнең контрольгә алынган элементлары коды | Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремне үтәү өчен максималь балл | Биремне үтәү өчен каралган якынча вакыт (мин.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Материкларның, океаннарның, җирдә яшәүче халыкларның географик үзенчәлекләрен белү һәм аңлау; төрле территорияләрне һәм акваторийларны хуҗалыкчыл яктан үзләштерүдәге аермалар; танылган географик ачышлар һәм сәяхәтләрнең нәтиҗәләре | 1.6, 1.3 | 1.1–5.6 | Б | 1 | 1 |
| 2 | Россиянең географик хәленең үзенчәлеген белү | 1.7 | 5.1 | Б | 1 | 1 |
| 3 | Россия табигатенең үзенчәлеген белү һәм аңлау | 1.7 | 5.2 | Б | 1 | 2 |
| 4 | Геоэкологик проблемалар килеп чыгуның табигый һәм антропоген сәбәпләрен белү һәм аңлау; табигатьне һәм кешеләрне табигатьтәге хәвеф-хәтәрләрдән, техноген күренешләрдән саклау чаралары | 1.8 | 4.3 | Б | 1 | 2 |
| 5 | Россия хуҗалыгының төп тармаклары, табигать, хуҗалык зоналары һәм районнарының үзенчәлекләрен белү һәм аңлау | 1.7 | 5.4, 5.5 | Б | 1 | 2 |
| 6 | Ресурсларны, аларны файдалану, сакһәм саклауны, халыкның яшәеш шартларына бәйле формалашкан мәдәни- | 2.6, 2.7 | 5.2, 5.3, 3.2 | Б | 1 | 2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | көнкүреш үзенчәлекләрне тәртипкә китерү | | | | | |
| 7 | Төрле чыганаклардан экология проблемасын өйрәнү өчен кирәк булган мәгълүматларны табу. | | | | | |
| 8 | Җирнең төрле территорияләрен өйрәнү, аларның табигый һәм өчен кирәкле мәгълүматны таба белү кеше ресурслары белән тәэмин ителешен белү | 2.7 | 5.3, 2.4, 5.4 | Б | 1 | 2 |
| 9 | Җирнең төрле территорияләреналарның табигый һәм кеше ресурслары белән тәэмин ителешен өйрәнү өчен кирәкле булган төрле чыганаклардагы мәгълүматны анализлый белү | 2.8 | 5.3, 2.4, 5.4 | П | 1 | 3 |
| 10 | Геосферадагы географик күренешләрне һәм процессларны аңлау | 1.4 | 2.4 | Б | 1 | 3 |
| 11 | Җирнең төрле территорияләрен өйрәнү өчен кирәк булган мәгълүматны анализлый белү | 2.8 | 2.4 | Б | 1 | 3 |
| 12 | Геоэкологик проблемлар килеп чыгуның табигый һәм антропоген сәбәпләрен белү һәм аңлау | 1.8 | 4.1, 4.2 | Б | 1 | 3 |
| 13 | Географик объектлар һәм күренешләрнең әһәмиятле үзенчәлекләрен аера (таный) белү | 2.2 | 2.2-2.6, 5.3 | Б | 1 | 3 |
| 14 | Картада географик координаталарны билгели белү | 2.1 | 1.1 | П | 1 | 3 |
| 15 | Географик объектларның һәм күренешләрнең әһәмиятле билгеләрен аңлата белү. Геоэкологик проблемалар барлыкка | 2.4, 1.8 | 2.2-2.6, 4.1 | В | 2 | 14 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | килүнең табигый һәм антропоген сәбәпләрен белү һәм аңлау | | | | | |
| 16 | Төп термин һәм төшенчәләрне белү һәм аңлау; алган белемнәрне һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта гамәли мәсьәләләрне чишүдә кулана белү | 1.1, 3.3 | 2.3, 2.4, 3.3, 5.4 | Б | 1 | 3 |
| 17 | Осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көнкүреш тормышта файдалана белү | 3.2 | 5.3 | П | 1 | 3 |
| 18 | Картада аралыкны билгели белү | 2.1 | 1.1 | Б | 1 | 3 |
| 19 | Картада юнәлешләрне билгели белергә тиеш | 2.1 | 1.1 | Б | 1 | 3 |
| 20 | Алган белем һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта үзе яшәгән җирлектәге әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын билгеләү, аннан файдалану буенча гамәли мәсьәләләрне чишү өчен куллана белергә тиеш | 3.3 | 1.1 | П | 2 | 14 |
| 21 | Алган белем һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта төрле эчтәлекле карталар уку өчен кулана белергә тиеш | 3.2 | 1.1 | В | 1 | 6 |
| 22 | Төрле чыганаклардан географик объект һәм күренешләрне өйрәнү өчен кирәкле мәгълүматны таба белергә тиеш | 2.7 | 1.1, 5.5 | Б | 1 | 2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 23 | Хуҗалыкның табигый-хуҗалык зоналары һәм районнарның төп тармакларының үзенчәлекләрен белергә һәм аңларга тиеш | 1.7 | 5.4 | В | 1 | 10 |
| 24 | Алган белем һәм осталыкларны гамәли эшчәнлектә һәм көндәлек тормышта вакыт поясын билгеләгәндә куллана белергә тиеш | 3.1 | 5.1 | П | 1 | 4 |
| 25 | Россиянең табигате, халкы, хуҗалыгының төп тармаклары, табигый-хуҗалык зоналары һәм районнарының үзенчәлекләрен белү, аңлау; географик урыны, табигый шартлары, ресурслары һәм аерым илләр белән хуҗалык бәйләнешләрен белергә тиеш | 1.6, 1.7 | 5.5, 3.3 | П | 1 | 5 |
| 26 | Геосферадагы географик күренешләрне һәм процессларны белергә һәм аңларга тиеш | 1.4 | 2.2 | Б | 1 | 3 |
| 27 | Җирнең төрле территорияләрен өйрәнү өчен кирәкле мәгълүматны анализлый белергә тиеш | 2.8 | 2.4 | П | 1 | 4 |
| 28 | Бәйлелек үлчәнешенең төрле формада чагылдырылган нәтиҗәләре нигезендә бәйлелекне ачыклый белергә тиеш | 2.9 | 2.1, 2.4 | П | 1 | 6 |
| 29 | Җир хәрәкәтенең географик нәтиҗәләрен | 1.4 | 2.1 | П | 1 | 3 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 30 | Географик объектларның һәм күренешләрнең әһәмиятле билгеләрен аера (таный) белергә | 2.2 | 2.6, 3.3, 5.3, 5.5 | П | 1 | 6 |
| Барлык биремнәр саны – **30**; аларның:<br>бирем типлары буенча: кыска җаваплы– **27**; киңәйтелгән җаваплы– **3**;<br>катлаулылык дәрәҗәсә буенча: Б – **17**; П – **10**; В – **3**.<br>Максималь беренчел балл – **32**.<br>Эшне башкаруга бирелгән гомуми вакыт – **120 минут**. | | | | | | |

© 2016 Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте